КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 21 август г.Казань № 622

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дубайдагы (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) сәүдә-икътисад вәкиллеген гамәлгә кую турында» 2013 ел, 30 май, 364 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дубайдагы (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) сәүдә-икътисад вәкиллеген гамәлгә кую турында» 2013 ел, 30 май, 364 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 июль, 499 нчы, 2013 ел, 31 декабрь, 1128 нче, 2014 ел, 8 февраль, 81 нче, 2022 ел, 21 ноябрь, 1243 нче, 2024 ел, 27 июнь, 475 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 25 апрельдәге 197 номерлы боерыгын үтәү өчен, шулай ук Татарстан Республикасының Дубай әмирлеге (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) белән үзара файдалы элемтәләрен алга таба үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына 60 көн эчендә Татарстан Республикасының Дубайдагы Сәүдә-икътисадый вәкиллеге (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) уставын расларга һәм уставны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу буенча кирәкле чараларны гамәлгә ашырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин